**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» август, 2020 ел № 1046

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче
гражданга туры килә торган керемнең
һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче
граждан милкендәге һәм 2020 елның
III кварталына салым салынырга тиешле
мөлкәт хакының максималь күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак коды, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның 29 июнендәге 351/пр номерлы «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2020 елның икенче яртыеллыгына бәясе нормативы һәм 2020 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» боерыгына таянып Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

Гражданнарны наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен максималь күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:Установить максимальные значения для принятия решения о признании граждан нуждающимися в предоставлении жилого помещения по договору найма:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 346 878,50 сум

1.2.1. Ике кешелек гаилә өчен - 1 714 209 сум

1.3.1. Өч кешелек гаилә өчен - 2 203 983 сум

1.4.1.Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2 938 644 сум

1.5.1. Биш кешелек гаилә өчен - 3 673 305 сум

1.6.1. Алты кешелек гаилә өчен - 4 407 966 сум

1.7.1. Җиде кешелек гаилә өчен - 4 407 966 сум

1.8. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләме:

1.8.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 19 374,36 сум

1.8.2. Ике кешелек гаилә өчен - 12 329,14 сум

1.8.3. Өч кешелек гаилә өчен - 10 567,83 сум

2. Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә

Питрәч муниципаль районы наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән максималь күләмнәрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Район башкарма
комитеты җитәкчесе

А. В. Хәбибуллин